Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының чираттан тыш утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары

29 май, 2019 ел № 203

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2011 елның 29 декабрендәге 78 номерлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 3 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 2 бүлекнең 17 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 2 бүлекнең 18 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.4. 2 бүлекнең 19 пунктында «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент белән хезмәттәшлек итү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1633605407